**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

16.01.2020

№ 8

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2014 елның 13 декабрендәге 707 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 30 июлендәге 439 номерлы, 2016 елның 5 апрелендәге 221 номерлы, 2017 елның 9 гыйнварындагы 2 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге 342 номерлы, 2017 елның 16 декабрендәге 731 номерлы һәм 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Эш төркеме составыннан А.Ф. Закировны, А.Р. Зариповны, М.Н. Зариповны, И.Н. Павловны, А.Р. Шәфигуллинны чыгарырга;

Эш төркеме составына кертергә:

Михайлов Андрей Вячеславовичны – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасының баш суд приставы урынбасарын (килешү буенча);

Розенталь Андрей Николаевичны – Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Соколов Алексей Владимировичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгын (килешү буенча);

Столяров Станислав Олеговичны – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча дүртенче бүлеге җитәкчесен (килешү буенча);

Нуриәхмәтов Илдар Сәлим улын – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча бишенче бүлеге җитәкчесен (килешү буенча);

Эш төркеме әгъзасы Р.В. Гыйльмановның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре», аны Эш төркеме рәисе итеп расларга.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ